**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**«Мюдовское сельское поселение»**
**423063 п. Мюд, ул. Центральная д 35**
**тел. 884344 4-04-33**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай**
**муниципаль районы**
**муниципаль беремлеге**
**"Мюд авыл җирлеге"**
**423063 Мюд авылы**
**Центральная урамы, 35**
**тел. 884344 4-04-33**

КАРАР

**№ 75** **23.05.2024 ел**

**Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты , Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 19.08.2010 № ЯК-7-8/393 “Түләнүгә өметсез дип танылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләп бетерүне ышанычсыз дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеге” боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Җирле салымнар суммасы (алга таба бурыч)буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;
- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Салым түләүченең бурычын исәптән чыгару салым органы тарафыннан әлеге карар һәм җирле салымнар суммалары буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар нигезендә башкарыла:
1) әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;
в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;
2) әлеге карарның 1.2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;
3) әлеге карарның 1.3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. 2023 елның 13 июнендәге 56 номерлы «бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре, пенялар буенча бурычлар һәм җирле салымнар буенча штрафлар турында»карарны үз көчен югалткан дип танырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мюд авыл җирлеге Советының финанслар һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: Т.В. Зюзина